ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

17.06.2024 № 538

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 19 сентябрендәге 2310 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими нигездә дәүләт серенә керү рөхсәт ителгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр һәм шәһәр округлары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 сентябрендәге 2310 номерлы карары (23.11.2020 № 887, 09.11.2022 № 1063

редакции) белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән, аларны яшерү, шулай ук шифрлар белән эшләү өчен елына 1,2 вазыйфаи оклад күләмендә өстәмәләр. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләү өчен күрсәтелгән айлык өстәмә, законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә рөхсәт рәсмиләштерү шарты белән, даими нигездә дәүләт серенә керү рөхсәт ителгән хезмәткәрләргә түләнә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин